**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 9 июнь № 387

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр), ачыкланган мәдәни мирас объектлары территорияләрендә халык белән чара үткәрү тәртибен раслау турында” 2013 ел, 4 декабрь, 953 нче карары белән расланган Мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр), ачыкланган мәдәни мирас объектлары территорияләрендә халык белән чара үткәрү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр), ачыкланган мәдәни мирас объектлары территорияләрендә халык белән чара үткәрү тәртибен раслау турында” 2013 ел, 4 декабрь, 953 нче карары белән расланган Мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр), ачыкланган мәдәни мирас объектлары территорияләрендә халык белән чара үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Халык белән чара үткәрү турында хәбәрләмә (тиз җыела торган җыйма-сүтмә конструкция кулланмыйча гына бер катнашучы үткәрә торган җыелыш һәм пикеттан тыш) халык белән чара үткәрелгән көнгә кадәр иң күбе 15 көн алдан һәм 10 көннән дә соңга калмыйча аның оештыручысы тарафыннан язма рәвештә вәкаләтле органга тапшырыла.

Җәяүлеләр һәм транспорт чаралары хәрәкәте өчен каршылык тудыра торган тиз җыела торган җыйма-сүтмә конструкция кулланып затлар төркеме тарафыннан пикет яисә бер катнашучы тарафыннан гамәлгә ашырылган пикетны үткәргәндә халык белән чара үткәрү турында хәбәрләмә аны үткәрү көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча, әгәр күрсәтелгән көннәр якшәмбе һәм (яки) эш көне булмаган бәйрәм көненә (эш көне булмаган бәйрәм көннәренә) туры килсә – аны үткәрү көненә кадәр дүрт көннән дә соңга калмыйча тапшырыла. Әгәр халык белән чара

үткәрү турында хәбәрләмә бирү вакыты тулысынча эш көне булмаган бәйрәм көннәренә туры килсә, хәбәрләмә эш көне булмаган бәйрәм көннәренә кадәр булган соңгы эш көнендә тапшырылырга мөмкин.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков